ГЛАВА ШИШИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ШЕҢШЕҢӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
25.12.2025

КАРАР
№ 6

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 17.12.2025 №28 карары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 29.05.2020 №130 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының “Шеңшеңәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең чикләрен туры китерү мәсьәләсе буенча, гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән, гражданнарның фикер алышуларда катнашу хокукларын үтәү максатларында, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чиген Киров өлкәсе белән чиктәш Татарстан Республикасы чигенә туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны 2026 елның 14 январена 11.00 сәгатькә, түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы,Шеңшеңәр авылы, Г.Тукай ур., 57 нче йорт.
2. Гавами тыңлауларда тикшерелә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, 2026 елның 13 январена кадәр, түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Шеңшеңәр авылы, Г.Тукай урамы, 60 нчы йорт (Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасы). Консультация өчен телефон: 8(843)68-3-98-57; 8(843)68-3-98-24.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), «ХЕЗМӘТ» басма газетасында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (https://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән һәм Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә:
   - Шеңшеңәр авылы, Г.Тукай урамы, 60 нчы йорт;
   - Ор авылы, М.Җәлил урамы, 45 нче йорт.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Салихҗанов